КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 июнь г.Казань № 673

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының патриотик тәрбия буенча координация советын төзү турында» 2018 ел, 12 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының патриотик тәрбия буенча координация советын төзү турында» 2018 ел, 12 февраль, 77 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 3 июнь, 463 нче; 2020 ел, 21 февраль, 126 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче; 2022 ел, 28 март, 278 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының патриотик тәрбия буенча координация советы турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Координация советы составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Координация советы рәистән, рәистәштән, рәис урынбасарларыннан, җаваплы сәркатиптән һәм Координация советы әгъзаларыннан тора.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Координация советы рәисе – Координация советы эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Координация советы рәистәше – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор. Алар булмаганда яки аларның кушуы буенча җитәкчелек вәкаләтләре Координация советы рәисе урынбасарына тапшырылырга мөмкин. Агымдагы оештыру мәсьәләләрен хәл итү белән җаваплы сәркатип шөгыльләнә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының патриотик тәрбия буенча координация советы составында:

Координация советы составыннан Д.А.Басариевны, И.Ш.Галиевны, Р.Р.Кыямовны, Т.Д.Сөләймановны, Г.Р. Шакированы чыгарырга;

Координация советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры, Координация советы рәисе урынбасары Ринат Наил улы Садыйковны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Раушан Булат улы Зариповны;

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары Айгөл Азат кызы Сабированы;

Ләйсән Камил кызы Алиуллинаның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары секретариатының баш киңәшчесе»;

Виктор Николаевич Демидовның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор, Координация советы рәистәше»;

Алла Андреевна Кондратьеваның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының «Движение первых» балалар һәм яшьләр гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлеге советы рәисенең беренче урынбасары»;

Екатерина Игоревна Согринаның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Балалар оешмалары советы» төбәк иҗтимагый оешмасы директоры, Казан шәһәренең «Яшүсмер» яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары берләшмәсе» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе директоры».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин